КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 20 сентябрь г.Казань № 851

Җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр формалаштыру, бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр формалаштыру, бирү һәм бүлү кагыйдәләрен расларга.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына 2019 елның 1 октябренә кадәр җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү һәм бүлү тәртипләренә (кагыйдәләренә) үзгәрешләр кертү турындагы норматив хокукый актлар проектларын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына аларны бу карарга туры китерү максаты белән билгеләнгән тәртиптә кертергә.

3. Бу карар, 2020 елга (2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына) бюджетлардан башлап, Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 20 сентябрь, 851 нче
карары белән расланды

Җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан
субсидияләр формалаштыру, бирү һәм бүлү
кагыйдәләре

1. Бу Кагыйдәләр муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр (алга таба – субсидияләр, муниципаль берәмлекләр) формалаштыруга, бирүгә һәм бүлүгә карата гомуми таләпләрне, шулай ук муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәсе күләмен финанслашуның иң чик дәрәҗәсен (процентларда) ачыклау һәм билгеләү тәртибен билгели.

Бу Кагыйдәләр түбәндәге субсидияләрне бирүгә кагылмый:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фондыннан;

финанслар белән тәэмин итү чыганагы булган Россия Федерациясе Президентының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фондлары исәбеннән бюджетара трансфертлар.

2. Субсидияләр җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен үтәгәндә финанс ярдәме күрсәтү максатларында, җирле үзидарә органнарының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрен үтәүне финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган, чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы белән раслана торган җирле бюджетларга субсидияләр исемлеге нигезендә бирелә.

Җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү һәм бүлүнең бу Кагыйдәләрнең 3 нче пункты нигезендә эшләнгән һәм расланган кагыйдәләре (тәртипләре) белән бер үк вакытта муниципаль милектәге капиталь төзелеш объектларына (алга таба – капиталь төзелеш объектлары) капитал салуларны, күчемсез мөлкәт объектларын (алга таба – күчемсез мөлкәт объектлары) муниципаль милеккә сатып алуны, капиталь төзелеш объектларына капитал салуларга һәм күчемсез мөлкәт объектларын сатып алуга кертелмәгән чараларны финанслашуга яки Татарстан Республикасының бер дәүләт программасы (Татарстан Республикасы дәүләт программасының ярдәмче программасы) кысаларында ике һәм аннан да күбрәк чараны финанслашуга субсидия бирү күздә тотылган очракта, бу Кагыйдәләрнең максатлары өчен мондый субсидияләр берләштерелгән субсидияләргә карый һәм аларга карата бу берләштерелгән субсидия турындагы кагыйдәләр нигезләре кагыла.

Субсидияләр бирү шартлары, субсидияләр бирү өчен муниципаль берәмлекләрне сайлап алу һәм аларны муниципаль берәмлекләр арасында бүлү критерийлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актлары белән билгеләнә.

3. Бюджетны планлаштыру субъектлары бу Кагыйдәләр нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының субсидияләр бирү кагыйдәләрен билгели торган яки элегрәк расланган субсидияләр бирү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертә торган норматив хокукый актлары проектларын әзерли, алар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына билгеләнгән тәртиптә кертелә.

4. Субсидияләр бирү кагыйдәләре түбәндәге нигезләмәләрне үз эченә алырга тиеш:

а) субсидияләрнең максатчан билгеләнешен;

б) субсидияләр бирү шартларын;

в) субсидияләр бирү өчен муниципаль берәмлекләрне сайлап алу критерийларын. Субсидияләр акчасы исәбеннән финанслашуы гамәлгә ашырыла торган чараларны тормышка ашыру өчен муниципаль берәмлек тарафыннан билгеләнгән акча күләмен субсидияләр бирү өчен муниципаль берәмлекләрне сайлап алу критерийлары сыйфатында куллану рөхсәт ителми.

г) муниципаль берәмлекнең тиешле чараларын финанслауга карата булган ихтыяҗга пропорциональ рәвештә (муниципаль берәмлектәге халык санынннан (халыкның аерым төркемнәреннән – соңгы социаль хезмәт күрсәтүләрне файдаланучылардан) һәм (яки) тиешле чараларны тормышка ашыру (объектлар төзү) чыгымнарын микъдари бәяләүдән һәм (яки) башка критерийлардан чыгып) һәм, Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләрен финанслашуның иң чик дәрәҗәсен исәпкә алып, субсидия күләмен билгеләүне күздә тота торган муниципаль берәмлекләр бюджетлары арасында субсидияләр бүлү методикасын;

д) субсидияләрдән файдалануның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен, шулай ук муниципаль берәмлек бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү турындагы килешү (алга таба – килешү) белән мәгънәләре билгеләнә торган субсидияләрдән файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләре (нәтиҗәләре) исемлеген. Берләштерелгән субсидияләргә карата субсидияләрдән файдалануның нәтиҗәлелеге (нәтиҗәләре) күрсәткечләре чараларның һәм (яки) капиталь төзелеш объектларының (күчемсез мөлкәт объектларының) һәрберсе буенча карала;

е) килешү шартларын үтәмәгәндә муниципаль берәмлекнең финанс җаваплылыгы чараларын куллану нигезләрен һәм тәртибен, шул исәптән муниципаль берәмлекләр тарафыннан субсидияләр бирү шартларын һәм бу Кагыйдәләрнең 10 нчы пунктындагы «в» һәм «г» пунктчалары белән күздә тотылган субсидияләрдән максатчан һәм нәтиҗәле файдалану буенча йөкләмәләрне үтәмәгән очракта, субсидияләрне киметү тәртибен һәм аның иң чик күләмен.

5. Муниципаль берәмлекләр бюджетлары арасында субсидияләрне бүлгәндә финанс елында муниципаль берәмлек бюджетына бирелә торган субсидия күләме, муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләрен Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслашуның иң чик дәрәҗәсен исәпкә алып, финанс елында муниципаль берәмлекнең финанслашу максатларында субсидия бирелә торган чыгым йөкләмәләрен үтәүгә каралган акча күләменнән артмаска тиеш.

6. Субсидияләрнең максатчан билгеләнеше, муниципаль берәмлекләрнең финанслашу өчен субсидия каралган чыгым йөкләмәләреннән чыгып, субсидияләр бирү кагыйдәләре һәм килешүләр белән билгеләнә.

7. Капиталь төзелеш объектлары һәм күчемсез мөлкәт объектлары буенча субсидияләрне адреслы (объектлап) бүлү килешү белән билгеләнә.

8. Субсидияләр бирү кагыйдәләрендә субсидияләр бирү шартлары буларак түбәндәгеләр күздә тотыла:

а) муниципаль берәмлекнең финанслашу максатларында субсидия бирелә торган чаралар исемлеген раслый торган һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актлары таләпләренә туры килә торган муниципаль хокукый актлары булу;

б) җирле бюджетта (җирле бюджетның җыелма бюджет исемлегендә) муниципаль берәмлекнең финанслашу максатларында субсидия бирелә торган чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләре аларны үтәү өчен кирәкле күләмдә (Татарстан Республикасы бюджетыннан бирергә планлаштырыла торган субсидия күләмен кертеп) булу;

в) муниципаль берәмлекнең финанслашу максатларында субсидия бирелә торган чыгым йөкләмәләрен үтәү йөкләмәсен күздә тота торган килешү төзү һәм әлеге килешү белән каралган йөкләмәләрне үтәмәгән өчен җаваплылык.

9. Субсидияләр бирү килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.

10. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган субсидияләр бирү кагыйдәләре нигезендә төзелә торган килешү түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

а) бирелә торган субсидиянең күләмен, аны муниципаль берәмлек бюджетына күчерү тәртибен, шартларын һәм вакытларын, шулай ук җирле бюджетның тиешле чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләре күләмен;

б) муниципаль берәмлекнең финанслашу максатларында субсидия бирелә торган чыгым йөкләмәләрен үтәү өчен бу Кагыйдәләрнең 13 нче пункты белән күздә тотылган тәртип нигезендә финанслашуның иң чик дәрәҗәсен исәпкә алып билгеләнгән һәм җирле бюджетта каралган бюджет ассигнованиеләре күләменнән процентларда чагылдырылган финанслашу дәрәҗәсен;

в) субсидиядән файдалану нәтиҗәлелеге (нәтиҗәләре) күрсәткечләре мәгънәләрен, шулай ук муниципаль берәмлекнең аларга ирешү буенча йөкләмәләрен;

г) капиталь төзелеш объектлары һәм (яки) күчемсез мөлкәт объектлары исемлеген һәм муниципаль берәмлекнең төзелеш (реконструкция) чараларын башкару графигын үтәү яки әлеге объектларны билгеләнгән төзелеш (реконструкция) кыйммәте яки объектлар сатып алу кыйммәте чикләрендә сатып алу буенча йөкләмәләрен – капиталь төзелеш объектларын төзүне (реконструкцияләүне (шул исәптән реставрация элементлары белән), техник яңадан җиһазландыруны) финанслашуга һәм (яки) күчемсез мөлкәт объектларын сатып алуга бирелә торган субсидияләргә карата;

д) муниципаль милектәге капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау эшләрен башкару турындагы шартнамәдә (муниципаль контрактта) аванс түләүләрен тиешле шартнамә (муниципаль контракт) суммасының 30 процентыннан артмаган күләмдә билгеләү хакындагы (финанслашу максатларында субсидия бирелә торган) йөкләмәләрен;

е) муниципаль берәмлекнең күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр сыйфатына һәм алардан һәркем файдалана алу мөмкинлегенә карата билгеләнгән

таләпләрне үтәү буенча йөкләмәләре – муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча чыгым йөкләмәләрен финанслашуга бирелә торган субсидияләргә карата;

ж) муниципаль берәмлекнең аның финанслашу максатларында субсидия бирелә торган чыгым йөкләмәсен билгели торган муниципаль хокукый акты реквизитларын;

з) җирле бюджетның финанслашу максатларында субсидия бирелә торган чыгымнарын гамәлгә ашыру турындагы, шулай ук субсидияләрдән файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләре (нәтиҗәләре) мәгънәләренә ирешү турындагы һәм капиталь төзелеш объектларын проектлаштыру һәм (яки) төзү (реконструкцияләү (шул исәптән реставрацияләү элементлары белән), техник яңадан җиһазландыру) һәм (яки) күчемсез мөлкәт объектларын сатып алу чараларын башкару графигы үтәлеше турындагы хисап документларын тапшыру вакытларын һәм тәртибен;

и) муниципаль берәмлек ягыннан килешүне үтәү (үтәүне яраштыру) һәм хисап документларын тапшыру функцияләре йөкләнә торган җирле үзидарә органы күрсәтмәсен;

к) муниципаль берәмлек тарафыннан килешү белән каралган йөкләмәләрнең үтәлешен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибен;

л) муниципаль берәмлекнең бу Кагыйдәләрнең 15 нче, 19 нчы һәм 20 нче пунктлары нигезендә акчаны Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча йөкләмәләрен;

м) килешү шартларын бозган өчен якларның җаваплылыгын;

н) килешүнең үз көченә керүе турындагы шартны.

11. Объектларның исемнәрен, адресларын (булганда), объектларның егәрлеген, капиталь төзелеш объектларын (күчемсез мөлкәт объектларын) файдалануга тапшыру (сатып алу) вакытларын, әлеге объектларның кыйммәтен (иң чик кыйммәтен), шулай ук төзелеш (реконструкция) чараларын үтәү графигы һәм аңа туры килә торган аларны тормышка ашыруның һәр елы өчен чараларны финанслау графигын күрсәтеп, бу карарга теркәлгән объектлар исемлеге капиталь төзелеш объектларын төзүне (реконструкцияләүне (шул исәптән реставрацияләү элементлары белән), техник яңадан җиһазландыруны) финанслашу яки күчемсез мөлкәт объектларын сатып алу максатларында, субсидияләр бирү турындагы килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора.

12. Килешү, аңа үзгәрешләр кертүне һәм аны өзүне күздә тота торган килешүгә теркәлгән өстәмә килешүләр Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган бертип нигезендә төзелә.

Агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законына һәм (яки) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының тиешле финанс елында субсидия бирү өчен бюджет ассигнованиеләре күләмнәрен тәгаенләүне күздә тота торган хокукый актына үзгәрешләр кертелгән очракта, килешүгә тиешле үзгәрешләр кертелә.

Шулай ук капиталь төзелеш объектларын төзүнең (реконструкцияләүнең (шул исәптән реставрацияләү элементлары белән), техник яңадан җиһазландыруның) смета кыйммәте дөреслеген тикшерү нәтиҗәләре буенча финанслашуына субсидия бирелә торган капиталь төзелеш объектлары төзүнең (реконструкцияләүнең (шул исәптән реставрацияләү элементлары белән), техник яңадан җиһазландыруның)

смета кыйммәтен кимету һәм (яки) дәүләт контрактының яки муниципаль контрактның аны төзү хокукына торглар нәтиҗәләре буенча бәясен кимету килешүгә үзгәрешләр кертү өчен нигез булып тора

Капиталь төзелеш объектларын төзүнең (реконструкцияләүнең (шул исәптән реставрацияләү элементлары белән), техник яңадан җиһазландыруның) смета кыйммәтен киметкән очракта, субсидия килешү белән күздә тотылган финанслашу дәрәҗәсеннән чыгып билгеләнгән күләмдә бирелә.

13. Муниципаль берәмлекнең субсидия исәбеннән финанслаша торган чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү өчен җирле бюджетның бюджет ассигнованиеләре күләме, субсидиядән файдалану нәтиҗәлелеге (нәтиҗәләре) күрсәткечләренең килешү белән билгеләнгән мәгънәләренә ирешү зарурлыгыннан чыгып, муниципаль берәмлек бюджеты турындагы карар белән раслана (муниципаль берәмлек бюджетының җыелма бюджет исемлеге белән билгеләнә).

Муниципаль берәмлекнең берләштерелгән субсидия исәбеннән финанслаша торган чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү өчен муниципаль берәмлек бюджетының бюджет ассигнованиеләре күләме, чаралар һәм (яки) капиталь төзелеш объектлары (күчемсез мөлкәт объектлары) буенча бүлеп, муниципаль берәмлек бюджеты турындагы карар белән раслана. Җирле үзидарә органнарының чаралар һәм капиталь төзелеш объектлары (күчемсез мөлкәт объектлары) арасында муниципаль берәмлек бюджеты чыгымнарының әлеге күләмнәрен яңадан бүлүгә зарурлыгы булганда, мондый яңадан бүленеш муниципаль берәмлек бюджеты турындагы карарга яки муниципаль берәмлек бюджетының җыелма бюджет исемлегенә һәм килешүгә тиешле үзгәрешләр кертү юлы белән гамәлгә ашырыла.

Муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләрен Татарстан Республикасы бюджетыннан (Yi) финанслашуның иң чик дәрәҗәсе түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$Y_i = 99\% - 94\% \times \left(\frac{\text{ранг РБО}_i}{\Sigma_i}\right)^2,$$

монда,

ранг $\text{РБО}_i$ – i муниципаль районының, шәһәр округының Татарстан Республикасы Бюджет кодексына теркәлгән 5 нче кушымта нигезендә билгеләнгән һәм агымдагы финанс елына тигезләнгән хисаплы бюджет тәэминаты дәрәҗәсе буенча урыны. Муниципаль районнарның, шәһәр округларының хисаплы бюджет тәэминаты дәрәҗәләрен рангларга аеру арта бара торган итеп гамәлгә ашырыла, шул ук вакытта хисаплы бюджет тәэминаты дәрәҗәсе аз булган муниципаль районга, шәһәр округына 1 ранг бирелә;

$\Sigma_i$ – Татарстан Республикасында муниципаль районнар, шәһәр округлары саны.

Муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләрен Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслашуның иң чик дәрәҗәсе бөтен бер санга кадәр түгәрәкләнә.

Муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләрен Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслашуның иң чик дәрәҗәсе чираттагы финанс елына һәм план

чорына муниципаль берәмлекләр буенча ел саен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән раслана.

Субсидияләр бирү кагыйдәләрендә, әгәр дә муниципаль берәмлекнең бердән артыграк чараларны тормышка ашыруны (берничә капиталь төзелеш объектларына (күчемсез мөлкәт объектларына) капитал салуларны) күздә тота торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында субсидияләр бирелгән очракта, муниципаль берәмлекнең аерым чаралар (капиталь төзелеш объектлары (күчемсез мөлкәт объектлары) буенча чыгым йөкләмәләрен Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслашуның төрле дәрәҗәләрен килешүдә билгеләп булу мөмкинлеге турында нигезләмәләр булырга мөмкин.

Муниципаль берәмлекнең тулаем алганда барлык чаралар (капиталь төзелеш объектлары (күчемсез мөлкәт объектлары) буенча чыгым йөкләмәләрен финанслашу дәрәҗәсенең муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләрен Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслашуның иң чик дәрәҗәсеннән артуын күздә тота торган килешүләр төзү яки төзелгән килешүләргә үзгәрешләр кертү рөхсәт ителми.

14. Субсидия акчасын Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекләр бюджетларына күчерү килешү нигезендә Федераль казначылыкның территориаль органы тарафыннан Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә керүләрне исәпкә алу һәм аларны Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары арасында бүлү өчен ачылган счетлар буенча гамәлгә ашырыла.

15. Әгәр дә муниципаль берәмлек тарафыннан субсидия бирелә торган елның 31 декабренә әлеге Кагыйдәләрнең 10 нчы пунктындагы «в» пунктчасы нигезендә килешү белән күздә тотылган йөкләмәләрне үтәү бозылган булса һәм субсидия бирелә торган елдан соң килә торган елда субсидиядән файдалану нәтиҗәлелеге (нәтиҗәләре) күрсәткечләре мәгънәләренә ирешү турында хисап документларын килешү нигезендә тапшыра торган беренче датага кадәр әлеге бозулар бетерелмәгән булса, субсидия бирелә торган елдан соң килә торган елның 1 июненә кадәр җирле бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиешле акча күләме ($V_{возврата}$) түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$V_{возврата} = \left(V_{субсидии} \times k \times \frac{m}{n}\right) \times 0{,}1,$$

монда:

$V_{субсидии}$ – хисап финанс елында муниципаль берәмлек бюджетына бирелгән субсидия күләме;

k – субсидияне кире кайтару коэффициенты;

m – субсидиядән файдалану нәтиҗәлелегенең (нәтиҗәсенең) i-күрсәткеченә ирешмәү дәрәҗәсен чагылдыра торган индексы уңай мәгънәгә ия булган субсидиядән файдалану нәтиҗәлелеге (нәтиҗәләре) күрсәткечләре саны;

n – субсидиядән файдалану нәтиҗәлелеге (нәтиҗәләре) күрсәткечләренең гомуми саны.

16. Җирле бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиешле акча күләмен исәпләгәндә хисап финанс елында муниципаль

бөрәмлек бюджетына бирелгән субсидия ($V_{субсидии}$) күләмендә агымдагы финанс елының 1 гыйнварына файдаланылмый калган субсидия өлешенең күләме исәпкә алынмый.

17. Субсидияне кире кайтару коэффициенты түбәндәге формула буенча исәплəп чыгарыла:

$$k = \frac{SUM\ D_i}{m},$$

монда:

$D_i$ – субсидиядән файдалану нәтиҗәлелегенең (нәтиҗәсенең) i-күрсәткеченә ирешмәү дәрәҗәсен чагылдыра торган индекс.

Субсидияне кире кайтару коэффициентын исәпләп чыгарганда, субсидиядән файдалану нәтиҗәлелегенең (нәтиҗәсенең) i-күрсәткеченә ирешмәү дәрәҗәсен чагылдыра торган индексның бары уңай мәгънәләре генә кулланыла.

18. Субсидиядән файдалану нәтиҗәлелегенең (нәтиҗәсенең) i-күрсәткеченә ирешмәү дәрәҗәсен чагылдыра торган индекс түбәндәгеләр өчен билгеләнә:

а) факттагы ирешелгән мәгънәнең зур мәгънәсе субсидиядән файдалануның зур нәтиҗәлелеген чагылдыра торган субсидиядән файдалану нәтиҗәлелеге (нәтиҗәләре) күрсәткечләре өчен – түбәндәге формула:

$$D_i = 1 - \frac{T_i}{S_i},$$

монда:

$T_i$ – хисап көненә субсидиядән файдалану нәтиҗәлелеге (нәтиҗәсе) i-күрсәткеченең факттагы ирешелгән мәгънәсе;

$S_i$ – субсидиядән файдалану нәтиҗәлелеге (нәтиҗәсе) i-күрсәткеченең килешү белән билгеләнгән план буенча мәгънәсе;

б) факттагы ирешелгән мәгънәнең зур мәгънәсе субсидиядән файдалануның аз нәтиҗәлелеген чагылдыра торган субсидиядән файдалану нәтиҗәлелеге (нәтиҗәләре) күрсәткечләре өчен – түбәндәге формула:

$$D_i = 1 - \frac{S_i}{T_i}.$$

19. Әгәр дә муниципаль берәмлек тарафыннан субсидия бирелә торган елның 31 декабренә бу Кагыйдәләрнең 10 нчы пунктындагы «г» пунктчасы нигезендә килешү белән каралган йөкләмәләрне үтәү бозылган һәм субсидия бирелә торган елдан соң килә торган елның 1 апреленә кадәр әлеге бозулар бетерелмәгән очракта, әлеге йөкләмәләрне үтәү бозылган елга, капиталь төзелеш объектларын төзү (реконструкцияләү (шул исәптән реставрацияләү элементлары белән), техник яңадан җиһазландыру) һәм (яки) күчемсез мөлкәт объектларын сатып алу чараларын үтәү графигы бозылган муниципаль милек объектларына капиталь салуларны финанслашуга күздә тотылган акча күләменең 10 процентына туры килә торган акча күләме, Россия Федерациясе субъектларының әлеге муниципаль милек объектлары

буенча агымдагы финанс елының 1 гыйнварына файдаланылмый калган субсидия өлешенең күләмен исәпкә алмыйча, субсидия бирелә торган елдан соң килә торган елның 1 июненә кадәр җирле бюджеттан Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Муниципаль берәмлек тарафыннан бу Кагыйдәләрнең 10 нчы пунктындагы «в» һәм «г» пунктчалары нигезендә килешү белән күздә тотылган йөкләмәләр берьюлы бозылган очракта, бу пунктның беренче абзацы нигезендә билгеләнгән, муниципаль милек объектларына капитал салуларны финанслашуга субсидия күләменә туры килә торган акча күләме кире кайтарылырга тиеш.

20. Берләштерелгән субсидия бирелгән очракта, җирле бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиешле акча күләмен исәпләү бу Кагыйдәләрнең 10 нчы пунктындагы «в» һәм «г» пунктчалары нигезендә килешү белән күздә тотылган йөкләмәләрен үтәү бозылган һәр чара һәм (яки) капиталь төзелеш объекты (күчемсез мөлкәт объекты) өчен аерым, берләштерелгән субсидиядән файдалану нәтиҗәлелегенең (нәтиҗәләренең) мондый чара һәм (яки) капиталь төзелеш объекты (күчемсез мөлкәт объекты) өчен тиешле субсидия бирү кагыйдәләрендә күздә тотылган күрсәткечләрен куллануны исәпкә алып гамәлгә ашырыла. Кире кайтарылырга тиешле акчаның гомуми күләме бу Кагыйдәләрнең 15 нче һәм (яки) 19 нчы пунктлары нигезендә, үтәлешендә бозулар булган чараларның һәм (яки) капиталь төзелеш объектларының (күчемсез мөлкәт объектларының) һәрберсе өчен кире кайтарылырга тиешле акча күләме буларак билгеләнә.

21. Субсидияләр бирү кагыйдәләрендә, әгәр дә муниципаль берәмлеккә карата бу Кагыйдәләрнең 15, 19 һәм 20 нче пунктлары белән күздә тотылган җаваплылык чаралары кулланылса, агымдагы һәм (яки) чираттагы финанс елында субсидия күләмен киметүне күздә тота торган нигезләмәләр булырга мөмкин.

22. Муниципаль берәмлек тарафыннан субсидия максатчан файдаланылмаган һәм (яки) аны бирү шартларын бозылган, шул исәптән муниципаль берәмлек тарафыннан бу Кагыйдәләрнең 15 нче, 19 нчы һәм 20 нче пунктлары нигезендә акча Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылмаган очракта, аңа карата Россия Федерациясе бюджет законнары белән күздә тотылган мәҗбүр итүнең бюджет чаралары кулланыла.

23. Әгәр дә муниципаль берәмлек тарафыннан субсидия бирелә торган елның 31 декабренә бу Кагыйдәләрнең 10 нчы пунктындагы «б» пунктчасы нигезендә килешү белән күздә тотылган йөкләмәләрне үтәү бозылган булса, субсидия ($S_н$) бирелә торган елдан соң килә торган елның 1 июненә кадәр муниципаль берәмлек бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиешле акча күләме түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$S_н = S_ф - S_к \times K_ф,$$

монда:

$S_ф$ – контроль чара (тикшерү (ревизия) тәмамланган көнгә карата муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен бирелгән субсидия күләме;

$S_к$ – контроль чара (тикшерү (ревизия) тәмамланган көнгә карата җирле бюджет акчасын алучы тарафыннан муниципаль берәмлекнең финанслашу

максатларында субсидия бирелгән чыгым йөкләмәләрен үтәү өчен кирәкле муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләрен финанслашу шартлары кабул ителгән һәм үтәлеше бозылган бюджет йөкләмәләренең гомуми күләме;

$К_ф$ – килешү белән күздә тотылган тиешле чара (капиталь төзелеш объекты, күчемсез мөлкәт объекты) буенча муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләрен Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслашу дәрәҗәсен чагылдыра торган коэффициент.

24. Әгәр дә килешү нигезендә субсидия берничә чараны финанслашу (муниципаль берәмлекнең муниципаль милкендәге берничә капиталь төзелеш объектына һәм (яки) муниципаль берәмлекнең муниципаль милкенә күчемсез мөлкәт объектларын сатып алуга капитал салуларны гамәлгә ашыру) максатларында бирелсә, бу Кагыйдәләрнең 23 нче пунктында күрсәтелгән формула һәр чарага (объектка) карата кулланыла, ә муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләрен финанслашу шартларын бозып файдаланылган акча суммасы чаралар (объектлар) буенча алынган уңай нәтиҗәләрнең арифметик суммасы буларак билгеләнә.

25. Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүчеләр муниципаль берәмлекләр белән килешүләр төзүне һәм агымдагы финанс елының 1 мартына кадәр (агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы законга үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы үз көченә кергән көннән 45 көннән дә соңга калмыйча) төзелгән килешүләр реестрын Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына кертүне тәэмин итә.

26. Төзелгән килешүләр булмаган очракта, агымдагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән тиешле баш эш итүчегә каралган субсидияләрне бирү өчен Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы закон (чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакындагы Татарстан Республикасы законы белән) белән расланган тиешле муниципаль берәмлеккә субсидия күләменә тигез күләмдә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты резерв фондының бюджет ассигнованиеләрен арттыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары нигезендә яңадан бүленергә тиеш.

27. Муниципаль берәмлекләр тарафыннан субсидияләр бирү шартлары үтәлешен тикшерүдә тоту Татарстан Республикасы бюджеты акчасын баш эш итүчеләр һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

___